КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 сентябрь

г.Казань

№ 832

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 586 нчы; 2006 ел, 6 февраль, 43 нче; 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2006 ел, 1 декабрь, 585 нче; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2007 ел, 26 декабрь, 744 нче; 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 890 нчы; 2016 ел, 9 август, 549 нчы; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә, 2.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.3. Территориаль социаль яклау органы хезмәткәрне шифаханә-курорт юлламасын алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә ала:

индивидуаль шәхси хисапның иминият номеры (СНИЛС) турында мәгълүматлар;

гариза бирүченең гаилә составы турында вәкаләтле оешмалардан мәгълүматлар;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлар;

күчемсез мөлкәт турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре турында мәгълүматлар.

Мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылганнан соң шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүматлар ала.

Хезмәткәрләр үз теләге белән бу пунктның икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлары булган документларны гариза белән бергә һөнәр берлеге оешмасына (территориаль социаль яклау органына) тапшырырга хокуклы.

Территориаль социаль яклау органы бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлар һәм бу пунктның икенче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә кирәкле барлык документлар белән бергә гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә хезмәткәрне юллама алуга исәпкә кую турында яки аны бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) тиешле карар турында хезмәткәркә хәбәр итә.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин